## Òàáèãûé áàòûðëûê áåðêàé÷àí äà ìàòóðëûãûí жóéìûé

Очеркистлар арасында исә без Ш.Рәкыйпов исемен дә еш күрәбез. Àның бу жанрдагы төп табышлары Ватан сугышы каһарманнарын сурәтләүдә булды. Ш.Рәкыйпов, Ватан сугышында катнашып, авыр шартларда тиңсез батырлыклар күрсәтеп, Советлар Союзы Герое исемен, яки илнең башка мәртәбәле бүләкләрен алуга лаек булган ватандашларыбызны дөньяга таныта, аларның әдәби образларын иҗат итүгә күп көч куя. Татар әдәбиятына сугыш темасына иҗат ителгән күпсанлы очерклар биргән каләм иясе теманы төрле образлар аша ача, һәрьяклап яктырта, каһарманнарны сугыш афәтенең күп кенә четерекле сәхифәләрендә күрсәтеп бирә.

Рейхстаг стеналарына исемнәрен язган милләттәшләребез хакында укыганыбыз бар. Әмма Җиңү байрагы кадаган солдатларның фидакарьлеге турында дөньяга шактый еллар узгач кына билгеле була. Бу хакта төрле карашлар яши. Алар Михаил Егоров белән Мелитон Кантария булганмы, әллә Гази Заһитов, М.Минин, А.Лисименко, В.Фамильскийлармы, À.Áîáðîâ?. Ш.Рәкыйповның әлеге сер йомгагын чишүгә мөнәсәбәтле күп кенә мәкаләләре, чыгышлары бар. Алар вакытлы матбугат битләрендә урын алганнар[1]. Автор Гази Заһитовлар төркеменең кылган батырлыклары, байракны нәкъ менә аларның кадавын документлар, рәсми хатлар һәм башка ышанычлы фактлар белән дәлилли. Әдипнең Рейхстагка байрак кадаучылар турында туплаган материаллары, мәгълүматлары киң билгеле “Мәңге сакларга!” дип исемләнгән очеркының нигезендә ята. Әлеге әсәр үзәгендә кешелек өчен иң зур батырлыкны кылган, 30 апрельдә яралы килеш фашистлар оясы булган Рейхстаг түбәсенә беренче булып Кызыл Байрак кадаган каһарман Гази Заһитовның образы һәм батырлыгы тасвирлана.

Язучы үзенең героен гадәттән тыш шәхес буларак тәкъдим итми. Ул, “аучыларга хас булганча, атнага ике сүз әйтә торган йомыкый, юаш, түземле, сабыр холыклы булган. Кая инде андыйга кешене шаккаттыра торган батырлык?!,- дип, автор укучыны үз герое белән таныштыра башлый. Гази, башка күп иптәшләре кебек үк, болында ат көткән, печән чапкан, тайгага ауга йөргән; әтисеннән күреп, сихәтле дару үләннәре җыйган һәм, үсә төшкәч, укырга киткән. Врач булырга хыялланган ул. Һәркемгә юл ачык, иренмә, ялкауланма гына, һәм тырыш, сабыр Гази техникумга укырга керә”[2]. Ләкин сугыш аның матур хыялларын чәлпәрәмә китерә. Егет күңелендә явыз дошманга аяусыз үч, нәфрәт кабына – чикерткәне рәнҗетергә батырчылык итмәгән яшүсмер аяусыз үч алучы булып әверелә. Юкка гына аны иң хәтәр бурыч башкаручылар төркеменә сайлап алмаганнар, күрәсең. 136 нчы Армиянең пушка-артиллерия бригадасының “иң кыю, иң тәвәккәл егетләренә генә” Рейхстаг өстенә Җиңү Байрагы кадау бурычы йөкләнә. Исемлеккә кертелгән сугышчылар арасында – А.Лисименко, А.Бобров, М.Кантария, М.Егоров, М.Мининнар белән бергә Г.Заһитов та була.

“Киң күкрәкле, калын муенлы, таза, чибәр” . Бу – Газинең портреты. Гази төркеме төнге аудан беркайчан да буш кул белән кайтмый. Дошманның ут нокталарын Газидан да остарак табучы булмый. Төркемдәге иптәшләренә булган хөрмәте, игътибарлылыгы, мәрхәмәте Заһитовның үзенә дә сугышчылар тарафыннан изгелек булып кайта. Алар һәрвакыт бер-беренең ярдәмен тоеп сугышалар, берсен-берсе ышыклап дошманга каршы көрәшәләр.

Гази Заһитов, мәхшәр, җәһәннәмдә исән калып, госпитальдә дәваланып демобилизацияләнә. Туган якларына – Башкортстан АССРның Мишкә районы Яңакош авылына кайта. Тыныч тормышта, сугыш афәтләрен тизрәк күңеленнән чыгарып ташларга тырышкандай,

җиң сызганып эшкә тотына. Әмма 1953 нче елның 23 августында, авыл хуҗалыгы машиналары өчен запас частьләр алырга барганда, төнлә автомобиль һәлакатенә очрап, фаҗигале төстә һәлак була.

“1945 нче елның 30 апреленнән 1 майга каршы төндә бригаданың разведчиклар төркеме, Рейхстагка бәреп кереп, Берлин өстенә беренче булып Кызыл Байрак кадады. Рейхстагны алуда катнашучыларга – Германия башкаласы өстенә Кызыл Байрак кадаучыларга, шул исәптән яралы өлкән сержант Заһитовка Советлар Союзы Герое исеме бирү һәм хөкүмәт бүләкләре өчен мәгълүматлар әзерләп җибәрелде. (СССР Оборона министрлыгы архивы, фонд 136, 212465 тасвирлама, 23 бит)...”. Документ күчермәсен автор әсәрдә тулысы белән китерә. Димәк, Г.Заһитов төркеменең батырлыгы сугышның бу хәлиткеч көннәрендә профессиональ хәрби җитәкчеләр тарафыннан тиешенчә бәяләнә. Әмма бу олы исем каһарманыбызга бирелми. Шактый соңарып кына әлеге батырлык Кызыл Йолдыз ордены белән генә бәяләнә. “Табигый матурлык беркайчан да бәясен җуймаган кебек, тыйнак батырлык та адәм балаларын үзеннән читкә этәрми. Халкының мактанычы булган чын батырның каһарманлыгы, үз иленә кайчан әйләнеп кайтса да, соңламый диләр. Хак сүз болар”. Әлеге хәлгә үзе шундый бәя бирсә дә, хаклыкның тулысынча торгызылмавы Ш.Рәкыйповны борчый. Шушы хис аңа тикшеренүләр алып барырга, бу хакта киң җәмәгатьчелеккә җиткерергә көч бирә. Шул рәвешле, әлеге очерк Ватан сугышының бер эпизоды хакында хакыйкатьне ачып биргән мөһим документ дәрәҗәсенә күтәрелә.